**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**2025 елда Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларын үстерүгә өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы Рәисе премияләрен бирү турында**

Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларын үстерүгә өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы Рәисе премиясен бирү комитеты тәкъдимнәрен караганнан соң **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларын үстерүгә өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы Рәисе премияләрен түбәндәгеләргә бирергә:

1) Әхмәдишина Лилия Мөгамбәр кызына – Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Иҗтимагый советы рәисе, «Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе башлыгы урынбасары – мәгълүмат-методика бүлеге башлыгына;

2) Бородин Александр Ильичка – «Россия ветераннар берлеге» бөтенроссия ветераннар иҗтимагый оешмасының «Татарстан Республикасы ветераннар берлеге» республика ветераннар (инвалидлар) иҗтимагый оешмасы рәисе, «ЯШЬ АРМИЯ» бөтенроссия балалар-яшүсмерләр хәрби-патриотик иҗтимагый хәрәкәтенең төбәк бүлекчәсе башлыгына;

3) Титова Татьяна Алексеевнага – «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесе Халыкара мөнәсәбәтләр, тарих һәм Көнчыгышны өйрәнү институтының Халыкара мөнәсәбәтләр һәм дөнья тарихы югары мәктәбе Татарстан тарихы, антропология һәм этнография кафедрасы профессоры, «Россия антропологлары һәм этнологлары ассоциациясе» гомумроссия иҗтимагый оешмасының Татарстан төбәк бүлекчәсе рәисенә;

4) «АК БАРС СОЗИДАНИЕ» хәйрия фондына;

5) «Татарстан Республикасының Диңгезчеләр җыены» төбәк иҗтимагый оешмасына;

6) «Татарстан Республикасының мордва милли-мәдәни мохтарияте» төбәк иҗтимагый оешмасына;

7) «Хезмәт Кызыл Байрагы орденлы бөтенроссия сукырлар җәмгыяте» инвалидларның гомумроссия иҗтимагый оешмасы Татарстан төбәк иҗтимагый оешмасына;

8) «Россия юристлары ассоциациясе» гомумроссия иҗтимагый оешмасының Татарстан төбәк бүлекчәсенә.

2. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2025 ел, 30 октябрь
№ 898